# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2024 елның 22 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 22 ноябрендә 17.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2025 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге 1 төркем инвалидлар, көндезге уку йортлары студентлар, дүрт һәм аннан да күбрәк бала белән күп балалы гаиләләр, хөкем ителгәннәр, Украина территориясендә махсус хәрби операция катнашучылар һәм гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1. Махсуслаштырылган техниканы карап тоту «Беларус-82.1» тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
2. Зур Нөркәй авылында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту утларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү);
3. Зур Нөркәй авылында җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) ;
4. Зур Нөркәй авылында зират территориясен койма белән әйләндереп алу (төзелеш материаллары сатып алу, зират территориясен койма белән әйләндереп алу (килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
5. Зур Нөркәй авылының зиратларында агач кисү;
6. Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарны вакытлыча туплау урыннарын җыештыру (хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
7. Зур Нөркәй торак пунктында янгын гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру;
8. Зур Нөркәй авылында урамындагы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш салу белән чокырларны ремонтлау, таш ташу).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 366 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 195 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 195 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар жыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл жирлегенең Зур Нөркәй авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтижәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2025 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районынын Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә 1 төркем инвалидлар, көндезге уку йортлары студентлар, дүрт һәм аннан да күбрәк бала белән күп балалы гаиләләр, хөкем ителгәннәр, Украина территориясендә махсус хәрби операция катнашучылар һәм гаилә әгъзаларыннан тыш, жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1. Махсуслаштырылган техниканы карап тоту «Беларус-82.1» тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
2. Зур Нөркәй авылында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту утларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү);
3. Зур Нөркәй авылында жәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) ;
4. Зур Нөркәй авылында зират территориясен койма белән әйләндереп алу (төзелеш материаллары сатып алу, зират территориясен койма белән әйләндереп алу (килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
5. Зур Нөркәй авылының зиратларында агач кисү;
6. Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарны вакытлыча туплау урыннарын жыештыру (хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
7. Зур Нөркәй торак пунктында янгын гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру;
8. Зур Нөркәй авылында урамындагы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш салу белән чокырларны ремонтлау, таш ташу) – **кабул ителде.**

3. Гражданнар жыены нәтижәләрен Зур Нөркәй авыл жирлегенең Зур Нөркәй мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар жыенында рәислек итүче
Башкарма комитет житәкчесе вазифаларын башкаручы
Зур Нөркәй авыл җирлеге
Сарман муниципаль районы
Татарстан Республикасы
_______________ А.Н.Сабитов